| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 25 марты Кукмара ш. № 111

Кукмара муниципаль районы Советының 2017 елның 20 гыйнварындагы 80 номерлы карары белән расланган Гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү, аларның исемнәрен үзгәртү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Кукмара муниципаль районы Уставы нигезендә, дәүләт, республика, муниципаль район һәм (яки) иҗтимагый мөнәсәбәтләр үсешенә зур өлеш керткән һәм уңай йогынты ясаган күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар турында истәлекләрне саклау максатыннан, Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде**:

1. Кукмара муниципаль районы Советының 2017 елның 20 гыйнварындагы 80 номерлы карары белән расланган Гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү, аларның исемнәрен үзгәртү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.6 пунктының бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацлары нигезләмәләре предприятиеләргә һәм учреждениеләргә Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе хезмәт Геройлары исемнәрен бирү очракларына, «Ватан алдындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләнгән гражданнарга, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены, «Кукмара муниципаль районының

Мактаулы гражданины» исеме, «Кукмара муниципаль районы алдындагы казанышлар өчен» медале белән бүләкләнгән гражданнарга кагылмый».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев